КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 17 февраль г.Казань № 85

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым кате-горияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы; 2016 ел, 19 октябрь, 762 нче; 2018 ел, 15 февраль, 90 нчы, 2018 ел, 24 март, 166 нчы, 2020 ел, 12 май, 379 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацына «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе» сүзләреннән соң «һәм «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затларга» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның «а» пунктчасының бишенче абзацына «һәм «Камалыштгы Севастопольдә яшәүчее» тамгасы белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның өченче абзацында «Блокададагы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләреннән соң «һәм «Камалыштагы Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин